ISSN 0868-4545



Салават күпере



Башның эше бармы?

Аяклар йөри, куллар эшли, муен башны бора, ә баш үзе нишли? Баш үзе дә эшләргә тиеш. Ә ничек эшли соң ул? Баш уйлый, аның бар эше дә менә шул инде, ягъни уйлау.

Һәр нәрсәнең дә башы була. Менә июнь ае килеп җитте. Июнь - җәй башы. Йәле, башны эшләтик: җәйдән соң нинди фасыллар килә? Кыш, яз, көз. Әлеге фасылларның рәте-чираты чуалган бит, әйеме? Башыңны эшләтеп кара әле!

Инде янә башларны эшләтеп алыйк. Менә сиңа әйтемнәр, шуларның мәгънәләрен аңлат:

Авырткан башка тимер тарак.
Акылсыз баш аякка тынгылык бирми.
Акылсыз баш иясеннән каз көттерер.
Акылсыз башка алтын бүрек файда бирмәс.
Алтын өйдән баш кыйбат.
Алтынны таштан эзлә, акылны баштан эзлә.
Бармагың сыймаган җиргә башыңны тыкма.
Баш белән таш ярып булмый.
Баш бетмәсә, мал бетмәс.
Баштан колак узмас.
Бер башка караганда ике баш яхшырак.

Үз башың гына эшләп җиткермәсә, әлеге әйтем-мәкальләрне сиңа өлкәннәр аңлатырга булышсын, яме.

Рәссам Фәридә ХАСЬЯНОВА

© "Сабантуй" кулере, 2004 ел


1
Баштан тора эшнең башы,
Ахыры да баштан тора:
Баш бит уйлый,
Фикер йөртә,
План кора.
План кора:
Ямьле җәйләр килеп җитте –
Нишләрмен дип.
Уйнап кына йөрмәм инде,
Файдалырак берәр нәрсә
Эшләрмен дип.

Рәссам Фәридә ХАСЬЯНОВА

Әнә килә бер машина,
Бүрек кигән башына.
Кетәклеккә менгән идем,
Тавык типте башыма.

Кетәклеккә менеп, тавыкларны борчып йөрсәң, шулай була ул. Бик башлы булсаң, табышмак әйтәм, ә син җавабын тап.

Мамык юрган,
Кат-кат сырган,
Үзе суп-суык.
Ул нәрсә?
Җавабы: июнь аена калмый, эреп бетә.

Шундый матур бер күпер –
Кеше йөрми, ат керми.
Ул нәрсә?
Җавабы: син укып утырган матур журналның исеме.

Түгәрәк баш – акыллы баш.
Сиңа бик күп эшләр хас.
Әйдә, торма инде тик,
Әй син, баш!
Бу журналның һәр битен дә
Укыйсы бар.
Тизрәк инде, тиз бул –
Зиһен сандыгыңны ач!

Балалар бакчасында

Мәктәпләрдә укулар тәмамланды. Ә нәниләр әле бакчага йөрүләрен дәвам иттерәләр.

– Мәсук белән Мәсуга
Барганнар, ди, басуга.
Мәсуга кайтып киткән,
Кайсы калган басуда?
–Мәсук!
(Җиңелчә генә сугып алалар.)

Рәссам Алла АЙСИНА



Үрдәкләр ничек йөри?

УЕН

Балалар кулга-кул тотынышып түгәрәк ясыйлар. Ике бала уртага чыгып баса. Алар уенны алып баручылар һәм җыр башлаучылар булалар. Салмак көйгә түгәрәк буйлап җырлап, әйләнеп йөриләр. Җырның эчтәлегендә сүз нәрсә турында барса, шул хәрәкәтне бергәләп башкаралар.

Әйт, күгәрчен, син генә,
Киленнәр ничек йөри?
Ул шулай да ул болай,
Киленнәр йөри шулай.
(Яулык очларын тотып йөриләр.)

Әйт, күгәрчен, син генә,
Куяннар ничек йөри?
Ул болай да ул шулай,
Куяннар шулай йөри.
(Куян кебек сикереп йөриләр.)

Әйт, күгәрчен, син генә,
Үрдәкләр ничек йөри?
Ул болай да ул шулай,
Үрдәкләр шулай йөри.
(Чүгәләп йөриләр.)

Уен шул рәвешчә дәвам итә. Балалар бабайлар, әбиләр һ.б. булып йөриләр.



Әнәс КАРИ

Безнең сыер өебезне яхшы белә,
Көтүдән ул мөгри-мөгри кайтып керә.
Әйтерсең лә: «Мине каршы алыгыз! – ди,–
Мул итеп сөт алып кайттым, савыгыз!» – ди.



Табышмаклар:
Су түгел – сыек,
Кар түгел – ак.
Ул нәрсә?

Үлән ашый, май ташый.

Дүрт агай-эне тарталар,
Чиләк төбенә аталар.

Рәссам Алла АЙСИНА





Сәяхәтче күбәләк















Һәй, сагынган идем шул инде сине! Бик-бик зарыгып көткән идем, җәй кызы!

«Әй, күбәләк, күбәләк,
Очыйк әле бергәләп,
Уйныйк әле бергәләп», – дип әйтәсеңне көттем. Һәм күбәләк кызы шулай диде дә аллы-гөлле чәчәкле болын буйлап очып та китте. Матур җәй килеп җиткән иде инде.

Күбәләк кызы белә: җәй үзе икегә бүленә. Аның беренчесе юкә агачлары чәчәк атканчы (июль аеның беренче ун көннәре), икенче җәй юкә чәчәк атканнан соң башланып сентябрь урталарына чаклы дәвам итә.

Кайсы гына чәчәк янына туктап, кайсысын гына үбеп өлгермәк кирәк күбәләк кызына! Бигрәк күп алар. Һәммәсе матурлар, хуш ислеләр. Менә ак чәчәкле «йокы үләне» («Белая дрёма»). Ләкин ул йоклый. Әйе, әйе, көпәкөндез керфекләрен йомган һәм йоклап утыра. Исеме дә шуңа күрә «йокырсар». Ләкин ул төш җитүгә уянып китә һәм... һәм аннан тирә-юньгә хуш исләр бөркелә! Кичләрен яңгыр алдыннан бигрәкләр дә хуш исле ул! Шуңа күрә аның янына күпләп күбәләкләр җыйнала. Әгәр шулай икән, димәк, иртәгә яңгыр явачак! Менә бит хикмәт!

Фәрештә чәчәкләре, күке төкереге, шайтан таягы (чыпчык җилеме), кырлык чәчәкләре, карчыга үләне яки тырнак уты кебек чәчәкләр белән күрешеп чыга күбәләк кызы.

Чәчәк сәгатьләре

Шулай болын буйлап сәяхәт итә торгач, вакыт та шактый узгандыр инде. Ләкин сәгать ничә икәнлеген кайдан белергә соң? Әлбәттә, «болын сәгате»нә карап. Мәсәлән, кырлык (торица) чәчәгенә. Кырлык кызыл кыр канәфер чәчәгенең туганы. Әмма ул аңа охшамаган. Кырлыкның чәчәге сәгать 10 белән 11 арасында ачыла, төштән соң 3тә, 4тә ябыла.





Мәсәлән, Тырнак уты (Ястребинка) июнь аенда ук чәчәк ата һәм аның сары кәрҗиннәре иртәнге 6-7 сәгатьләрдә ачыла. Ә кичке сәгать 3тән соң ябылалар.

Рәссам Фәридә ХАСЬЯНОВА



Аннан соң Гөлбаба. Гөлбабаның (Кульбаба) чәчәкләре иртән 7дә ачыла, төштән соң сәгать 3тә ябыла. Менә сиңа мә! Болын буйлап йөргәндә сәгать тә кирәк түгел икән.

Һиндыба (Фәрештә чәчәге) исә чәчәкләрен иртәнге 5ләрдә үк ача башлый.



Гөлҗимешнең чәчәкләре исә иртәнге 4-5 сәгатьләрдә ачыла. Әгәр күзәтеп торсаң, аларның кояш артыннан «башларын борганын» күрәсең. Иртәнге 6-7 сәгатьләрдә бәрәңге чәчәкләре дә ачыла башлый, 2 дә яки 3тә алар ябыла инде.

Әлбәттә, бу хәлләр кояшлы көннәрдә генә күзәтелә.

Күрәсезме, һәр чәчәкнең үз сәгате бар икән.





Сабантуй


Сабантуй – татар халкының милли бәйрәме. Язгы чәчү эшләре беткәч була ул. Печән чабарга төшкәнче. Халкыбызның милли туе – Сабантуй.

Кышкы суыклар инде узган. Кояш нурлары җир йөзен назлый. Матур, җылы көннәр башланган чак.

Асыл кояш, кил бире,
Кил бире китмә кире.
Кошлар да көтә сине,
Тавыклар да кытаклый,
Ак үрдәкләр бакылдый,
Ата казлар каңгылдый,
Юлга чыккан сыерчык.

Бар да көтә, кояш чык!
Асыл кояш, җәһәт кил,
Яшел җәйне тизләп кил.





Әлеге рәсемнәрдә Сабантуйдагы нинди күренешләр сурәтләнгән?



Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ



Алдыбызда бит Президент



Казандагы 71 нче мәктәп укучысы Адилә Хөснуллина былтыр Арча Сабан туенда булды. Бәйрәмгә Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев тә килгән иде. Адиләнең Илбашын бик тә күрәсе килде. Ходайның рәхмәте, Адилә аны күреп кенә калмады, кызга Президент белән бергә фоторәсемгә төшү бәхете дә насыйп булды. Көтмәгәндә-уйламаганда Минтимер Шәймиев үзе килде алар янына. Адиләнең янәшәсендә кулына фотоаппарат тоткан бер абый басып тора иде.

Теге абый черт тә черт төшерә башлады. Фотоаппаратлы бу абый журналыбызның баш мөхәррир урынбасары Вакыйф Нуриев иде. Бүген бу фоторәсемне – Арча Сабан туе истәлеген – сез дә карый аласыз, дуслар. Президентның сул ягындагы абыегызның кем икәнен беләсегез килсә, Арча хакимияте башлыгы Алмаз Нәзиров ул. Уң ягында елмаеп торган матур кыз Адилә була инде.


Сабантуйда бии Илзирә дә




Былтыр без Балтач районы Кенәбаш авылы Сабан туенда булдык. Анда рәхәтләнеп биедек. Кечкенә сеңелебез Илзирә дә биеде. Иң яхшы биючегә бүләк тә әзерләп куйганнар. Бик матур кәрҗин. Беләсезме, кемгә бирделәр ул бүләкне? Илзирәгә! Сөенештек. Бу кәрҗин – аның Сабантуйда алган беренче бүләге.

Фирүзә ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА. 10 яшь.
Арча районы, Сөрнар урманчылыгы.


Фирүзә Сабантуйны рәсемгә дә төшереп җибәргән.





Илдар КАШАПОВ, 6 яшь.
Башкортостан, Илеш, Карабаш

Бу рәсемнәрне Яр Чаллы шәһәрендәге 16 нчы балалар бакчасына йөрүчеләр ясап җибәрде.



Айгөл МУЛЛАГАЛИЕВА, 7 яшь.



Айгөл РОМАНОВА, 7 яшь.



Катя ПАШКОВА, 7 яшь.

Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ



Авыл буйлап йөрим...

Шундый рәхәт миңа бүген
Урамда йөрүләре.
Куркыныч түгел казлар да,
Этләрнең өрүләре.

Бөтен кеше хөрмәт итә:
«Нихәл? Нихәл?» – дип тора.
Кайберләре, телсез калып,
Өнсез калып, тик тора...

Елгадагы басма аша
Беренче чыгаралар,
Кичә үртәшкән малайлар
Уйнарга чакыралар.

Күрше урам кызлары да
Матур итеп эндәшә.
...Авыл буйлап чыктым әле,
Акбай бара янәшә.

Яшел сөт буламы?

Авылга кайткан бер малай
Сыер карарга чыккан.
Әбисенә соравы бар,
Шуны сорарга чыккан:
– Бер чиләк сөт йөртә үзе,
Ничек кенә түгелми?
Яшел үлән ашаса да,
Сөте яшел түгел, – ди...



Рәссам Булат ГЫЙЛЬВАНОВ

Татар кошы

Бакчабызга бер кош килде,
Кушкаенны сайлады ул.
Күңелләрне моңландырып,
Өзеп-өзеп сайрады ул...

Бу кадәр моңлы булмаса,
Каенга да кунмас иде.
Әгәр... Әгәр кош булмаса,
Ул моңлы да булмас иде...

Нигә шулай сайрый соң ул,
Канат җәеп кушкаенга?
Нинди сагыш төште икән
Кеп-кечкенә башкаена?

Кош кына шул... Кеше булса,
Кайтыр иле булыр иде.
Әгәр сөйләр теле булса,
Татар теле булыр иде!..

Җәйге кар

Тупыл кар очыра,
Июль ае җиткән!..
Бу могҗиза-хәлгә
Карап торам читтән...

Малай-шалай уйчан,
Кызлар чыр-чу килә.
Бераз шомландыра,
Җанга борчу керә...

Тукта! Нидер булган –
Кем борынлый чаттан?
Күршедәге Рәсим
Чаңгы тотып чыккан...




Роза КОЖЕВНИКОВА

Тавыш

Бар минем бер яхшы танышым –
Авызым эчендәге тавышым.
Һич тынычлык бирми ул миңа,
Нәрсә әйтим дисәм – кысыла.
Малай булып көлә кайчакта,
Кызлар кебек көлә кайчакта.
Киреләнә, үрти, кылана,
Әйткәнне дә тыңлый кайчакта.

Ни дисәң дә үзе яхшы ул,
Минем тел очында яши ул.





Рәссам Лилия ЗОЛОНДИНОВА


Тәлгәшле йолдызлар

Зәңгәр күктән аланнарга
Йолдыз яуган.
Җиләк булып үскән алар
Һәм кызарган.

Йолдызларны җыеп салдык
Тырысларга.
Тырыс тулды, тиз булсын дип,
Тырышканга.

Йөгерә-йөгерә кайтып киттек
Без өйләргә.
Йолдызларның тәлгәшлесе
Әниләргә.

Индус СИРМАТОВ тәрҗемәсе.



Кояш ничек йоклый?



Кояшкай кайда йоклый?
Болындадыр, болында,
Кояшкай ничек йоклый?
Кояшкай ничек йоклый?
Башын куеп, башын куеп,
Башын куеп болытка.

Болытны эретер дә,
Күктән яңгыр түгелер.
Калкыр болын өстендә,
Калкыр болын өстендә
Салават, салават,
Салават күпере.

Ләис ЗӨЛКАРНӘЙ
тәрҗемәсе.

Төш

Тәти курчакларымны,
Бар уенчыкларымны
Назлап кулыма алам,
Мендәр астына салам.

Төнлә алар янына
Минем төшләрем килә,
Шуның өчен һәр төндә
Уенчыклар төш күрә.

Индус СИРМАТОВ
тәрҗемәсе.





– Карагыз әле безгә,
Күрегез әле безне:
Икәү фотога төшеп,
Шаккаттырдыкмы сезне?!

Башкортостан, Иске Җанегет.






– Йокларга дип яткан булдык –
Күз салыгыз безләргә:
Бер нишләр хәл юк инде –
Йокы керми күзләргә.

Казан.



– Тәмле конфетым бар минем,
Беркемгә бирмим әле.
Чәй эчкәндә сиңа гына
Бирермен, әни, яме!

Кукмара, Аш. Бузи.



– Гөрләшәбез, серләшәбез,
Чәй эчәбез бергәләп.
«Урын тар», дип торма инде,
Марат, утыр түргәрәк!

Азнакай.



– Икебез дә – шәһәр кызы,
Без – бик-бик-бик дус кызлар:
Мактанып әйтү түгел –
Без – җирдәге йолдызлар!

Әлмәт-Мәскәү.

Башваткыч

Ринат НУРУЛЛИН

Җиңү җиңел бирелми

(Багана очын кочып уйланулар)

Әкәм–төкәм әзерләнә
Сабантуй бәйрәменә.
Көн саен ул баганага
Биш метр өскә менә.

Төнлә төшә дүрт метрга
Тәүлек буе көнегә...
Нигә сөйлим мин боларны?
Ә сөйлим менә нигә!

Багананың биеклеге
Ун метр булса әгәр,
Ничә көннән Әкәм–төкәм
Очына менеп җитәр?

Җавабын көзге белән укы:
Алты көннән.

Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Сәлават күпере

6(171) — 2004

ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ: ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЖИР, МИЛЕК МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ ҺӘМ РЕДАКЦИЯ КОЛЛЕКТИВЫ.
1990 елның март аеннан бирле чыга.

УЧРЕДИТЕЛИ: МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РТ, ПРАВЛЕНИЕ СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ РТ И КОЛЛЕКТИВ РЕДАКЦИИ.
Основан в 1990 году.
На татарском языке.

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 96 нчы номер белән теркәлде.

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Баш мөхәррир урынбасары
Вакыйф НУРИЕВ

Җаваплы сәркатип
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Компьютер дизайны
Фидель ХӘСӘНОВ

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

Тышлыкта Алла АЙСИНА рәсеме.

Мәктәпкәчә яшьтәге һәм кечә яшьтәге мәктәп балалары өчен.

Адрес редакции:
420012 г. Казань, ул. Муштари, 14.
E-mail: ck-sxn@newmail.ru

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм тәсләргә бүленде.

«Идел-пресс» полиграфия нәшрият комплексы» дәүләт унитар предприятиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Производствога бирелде 17.05.2004 ел.
Басарга кул куелды 17.05.2004 ел.
Кәгазь форматы 60х100 1/8.
Гарнитура – Прагматика.
Офсет ысулы белән басыла.
Тиражы 12801 данә. Заказ Э-342.



Бәясе килешү буенча
Индекс 73953

Ләбиб Лерон

Колын-колынкай

Һай бу көннәр, һай бу төннәр
Бигрәкләр озак үтә –
Ярышка барасы атлар
Сабантуй көнен көтә.

Ат чабышы ничек узар –
Шуны беләсе килә:
Колынкайның Сабантуйны
Бик-бик күрәсе килә.